# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм "Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 31 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Теләче муниципаль районы составына керүче "Олы Мәтәскә авыл җирлеге" һәм "Теләче авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләре территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

"Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш); 2008, № 12 (VIII өлеш); 2010, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- җирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | | |
|---|---|---|
| 12(48)-22(49) | - | Арча муниципаль районы |
| 22(49)-1(51а) | - | Саба муниципаль районы |
| 1(51а)-2(52) | - | Кукмара муниципаль районы |
| 2(52)-3(53) | - | Мамадыш муниципаль районы |
| 3(53)-28(55) | - | Балык Бистәсе муниципаль районы |
| 28(55)-12(48) | - | Питрәч муниципаль районы |

"Теләче муниципаль районы"
муниципаль берәмлеге составына керүче
авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Әбде авыл җирлеге |
| 2 | Айдар авыл җирлеге |
| 3 | Алан авыл җирлеге |
| 4 | Баландыш авыл җирлеге |
| 5 | Олы Мәтәскә авыл җирлеге |
| 6 | Олы Мишә авыл җирлеге |
| 7 | Олы Нырсы авыл җирлеге |
| 8 | Югары Кибәхуҗа авыл җирлеге |
| 9 | Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге |
| 10 | Иске Җөри авыл җирлеге |
| 11 | Теләче авыл җирлеге |
| 12 | Үзәк авыл җирлеге |
| 13 | Шәдке авыл җирлеге"; |

2) 7 нче кушымтаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Олы Мәтәскә авыл җирлеге чиге Теләче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Мәтәскә, Кече Кибәхуҗа һәм Теләче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Теләче авылыннан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып 2,5 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 500 м чокыр төбе һәм аның кырыйлары буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба, Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә, юл буендагы урман полосаларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 350 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, чокыр башын һәм инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба, инешләрне һәм киптерү канавын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 900 м көнчыгышка таба, киптерү канавын кисеп үтеп, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба Олы Мәтәскә, Теләче һәм Үзәк авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Үзәк поселогыннан 800 м төньякта урнашкан 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.";

3) 13 нче кушымтаның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Теләче авыл җирлеге чиге Олы Мәтәскә авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Олы Мәтәскә, Кече Кибәхуҗа һәм Теләче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Теләче авылыннан 2,7 км төньяк-көнбатышта урнашкан 15 нче тоташу ноктасыннан алып 2,5 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 500 м чокыр төбе һәм аның кырыйлары буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,4 км көньяк-көнбатышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба, Казан – Шәмәрдән автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк чиге буйлап 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба уза, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтә, юл буендагы урман полосаларын кисеп үтеп, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 350 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 350 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м көньяк-көнчыгышка таба, чокыр башын һәм инешләрне кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 700 м төньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньякка таба, сынык сызык ясап, 1,7 км төньяк-көнчыгышка таба, 200 м төньяк-көнбатышка таба, инешләрне һәм киптерү канавын кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 900 м көнчыгышка таба, киптерү канавын кисеп үтеп, 1,0 км көньяк-көнчыгышка таба 16 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.".

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты


ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 18 апреле
№ 8-ТРЗ

"Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү турында һәм "Теләче муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына кушымта

Чикләре әлеге Закон нигезендә үзгәрүче муниципаль берәмлекләр территорияләренең карта-схемасы




Шартлы билгеләр

- муниципаль берәмлекләр чикләре

- торак пунктлар

А-Б - Олы Мәтәскә авыл җирлеге һәм Теләче авыл җирлеге чиктәш чиге

- Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Теләче муниципаль районы Теләче авыл җирлеге составына кертелүче территориясе